Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет майданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Совет города Арск
422000,г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

**Арча шәһәр Советы**

**карары**

**« 04 » октябрь 2016 ел** **№ 46**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны җыю һәм урнаштыру турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ, "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 10.01.2002 ел, № 7-ФЗ, "Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" 24.06.1998 ел, № 89-ФЗ Федераль законнарга, "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 03.09.2010 ел, № 681 "Россия Федерациясендә җитештерү һәм куллану калдыкларын, яктырту җайланмаларын, электр лампаларын тиешенчә җыю, саклау, куллану, зарарсызлау, ташу һәм урнаштыру кагыйдәләрен раслау турында" карарына таянып, җитештерү һәм куллану калдыкларын, яктырту җайланмаларын, электр лампаларын тиешенчә җыю, саклау, куллану, зарарсызлау, ташу һәм урнаштыру максатыннан Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны җыю һәм беренчел урнаштыру урыннары исемлеген түбәндәге адрес буенча расларга:

Җыю урыны адресы

1. 422000, ТР, Арча муниципаль районы, "Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге, Арча шәһәреннән 3,5 км төньяк-көнбатыштарак «Арча - Яңа Кенәр» автомобиль юлы буенча каты көнкүреш калдыклары полигоны.

2. Арча шәһәре Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә

терекөмешле лампаларны җыю һәм урнаштыру урыннары турында физик һәм юридик затларга мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Чын карар рәсми рәвештә чыгарылганнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ф. Касыймовка йөкләргә.

Арча шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев